РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

02.12.2022

№ 1253-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары тарафыннан үзара салым акчаларын түләү буенча матди ярдәм күрсәтү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар , Россия Федерациясенең милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затлар, Татарстан Республикасында төзелгән “Алга” һәм “Тимер” батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, махсус хәрби операция уздыру зонасына җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре арасыннан булган махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына социаль ярдәм күрсәтү максатларында , Россия Федерациясе Бюджет кодексының 74 статьясы, “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының “2022 елга һәм 2023-2024 елларның план чорына Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының бюджеты турында” 2021 елның 15 декабрендәге 101 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында”гы Саба муниципаль районы Советының 2022 елның 30 ноябрендәге 163 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары тарафыннан үзара салым акчаларын түләү буенча матди ярдәм күрсәтү тәртибе турындагы Нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары тарафыннан үзара салым акчаларын түләү буенча матди ярдәм күрсәтү өчен кирәк булган акчаларны карарга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2022 елның 23 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфаларын
башкаручы, Җитәкче урынбасары –
Саба муниципаль районы Башкарма
комитеты аппараты җитәкчесе М.Р. Кәримов

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2022 елның
2 декабрендәге 1253-п
номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары тарафыннан үзара салым акчаларын түләү буенча матди ярдәм күрсәтү тәртибе турында Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

**1.1.** Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар , Россия Федерациясенең милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затлар, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, махсус хәрби операция уздыру зонасына җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре арасыннан булган махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына социаль ярдәм күрсәтү шартларын һәм тәртибен билгели.

**1.2.** Үзара салым акчаларын түләү буенча матди ярдәм (алга таба - текст буенча - матди ярдәм) :

– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар , Россия Федерациясенең милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затлар, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, махсус хәрби операция уздыру зонасына җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләренә;

– мобилизацияләнгән гражданнарның гаилә әгъзаларына:Саба муниципаль районы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән хатынына, балигъ булган балаларына ;

– мобилизацияләнгән гражданнарның гаилә әгъзаларына: әнисенә һәм әтисенә, шулай ук яшәү урыны буенча мобилизацияләнгән граждан белән бергә теркәлгән хатынының әнисенә һәм әтисенә бирелә .

**1.3.** Матди ярдәм әлеге Нигезләмәнең 1.2 пунктында күрсәтелгән мобилизацияләнгән гражданнар, шулай ук аларның гаилә әгъзалары тарафыннан үзара салым акчаларын түләү максатларында бирелә.

**1.4.** Матди ярдәм күләме, гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карар нигезендә, торак пунктта кертелгән үзара салым күләмендә билгеләнә.

**1.5.** Әлеге карар нигезендә социаль ярдәм чараларын күрсәтүче җирле үзидарә органнары күрсәтелгән социаль ярдәм чаралары турында Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә социаль тәэминатның Бердәм дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба - ЕГИСО) куллану юлы белән һәм ЕГИСО операторы билгеләгән форматларга туры китереп мәгълүмат бирүне тәэмин итәләр.

**1.6.** Әлеге карарда күрсәтелгән гражданнарга социаль ярдәм чаралары турында мәгълүмат, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә Бердәм дәүләт мәгълүмат системасын куллану юлы белән һәм ЕГИССО операторы тарафыннан билгеләнгән форматларга туры китереп алынырга мөмкин.

## 2. Түләү алу тәртибе.

**2.1.** Матди ярдәм Саба муниципаль районы Советы карары белән расланган җирле бюджеттан акчалар бирү шартларын билгеләгән очракта, шулай ук бюджет ассигнованиеләрен һәм (яисә) бюджет йөкләмәләре лимитларын билгеләгән очракта Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - вәкаләтле орган) тарафыннан күрсәтелә.

**2.2.** Матди ярдәм вәкаләтле орган тарафыннан түбәндәге документлар нигезендә бирелә:

– Гражданинның Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар , Россия Федерациясенең милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затлар, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, махсус хәрби операция уздыру зонасына җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре арасыннан булган махсус хәрби операциядә катнашучы гражданин булуын раслый торган, хәрби комиссариат тарафыннан бирелгән документлар;

– Саба муниципаль районының авыл (шәһәр) җирлеге тарафыннан бирелгән яшәү урыны буенча теркәлгән мобилизацияләнгән гражданның гаилә әгъзалары турында мәгълүмат (белешмәләр);

– Саба муниципаль районы Башкарма комитетының ГХАТ бүлеге тарафыннан бирелгән туганлык мөнәсәбәтләрен раслаучы документлар;

– торак пунктта - мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча теркәлү үткәрелгән җирлекнең Башкарма комитетында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карар;

**2.3.** 2.2 пунктта күрсәтелгән кирәкле документларны җыю, шулай ук Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы тарафыннан бирү нигезләрен тикшерү башкарыла, нәтиҗәләр турында мәгълүмат Саба муниципаль районы Башкарма комитетына бирелә.

**2.4.** Алынган мәгълүматларга нигезләнеп, вәкаләтле орган 10 көн эчендә гражданнарга үзара салым акчасын түләү буенча матди ярдәм түләү турында карар кабул итә һәм тиешле карарны алучыларга (шәхси очрашу, хат язу, смс-хәбәр, электрон почта) җиткерә.

**2.5.** Матди ярдәм вәкаләтле орган карары кабул ителгәннән соң 3 эш көне дәвамында түләнә.

**2.6.** Матди ярдәм алучының банк счетына күчерелә яки акчалата бирелә.

**2.7.** Вәкаләтле орган, шулай ук Саба муниципаль раойнының Финанс-бюджет палатасы документларның чынлыгында һәм тапшырылган белешмәләрнең дөреслегендә шик туган очракларда бирелгән вәкаләтләр чикләрендә органнар тарафыннан тапшырылган белешмәләрне өстәмә тикшерергә хокуклы.

**2.8.** Түләү бирү мәсьәләләре буенча бәхәсләр суд тәртибендә хәл ителә.